РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИХАЙЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА МИХАЙЛОВКА ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

---

**Карар № 2**

Михайловка авылы “17” январь 2024 ел.

**2023-2024 елларга кар туплау урыннарын билгеләү турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы таләпләренә ярашлы рәвештә, Михайловка авыл җирлеге Уставына һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге территориясендә юлларны, урамнарны, мәйданнарны вакытында чистартуны тәэмин итү максатларында «Төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләренә» таянып Михайловка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Михайловка һәм Элемтә авылларыннан чыгарылган карның туплану урыны итеп Элемта авылы янында урнашкан 1079 кв.м. мәйданлы бушлыкны билгеләргә, кадастр номеры 16:29:160201:74 булган җир участогында.
2. Михайловка авыл җирлеге башкарма комитетына ел саен:

2. 1. мәйданчыкны карны вакытлыча җыю өчен һәм аңа керү юлларын әзерләү;

2. 2. кар эрү чоры тәмамланганнан соң вакытлыча кар туплау мәйданчыгы территориясен рекультивацияләүне һәм чистартуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга:http://pravo.tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.
5. Әлеге карар имзаланганнан соң үз көченә керә.

Михайловка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Н.А. Ращупкина